**Рус телендә белем бирү мәктәпләренең 2 нче сыйныф укучылары өчен туган (татар) телдән**
**агымдагы аттестацияне уздыру**
**материалларының күрсәтмә варианты**

**Демонстрационный вариант**
**контрольных измерительных материалов для проведения**
**промежуточной аттестации**
**по родному (татарскому) языку для учащихся 2 классов**
**школ с русским языком обучения**

**Эшне башкару өчен күрсәтмә**

Биремнәрне башкару өчен, 45 минут вакыт бирелә. Тест 10 **биремне** үз эченә алган **5** бүлектән тора.

**1 нче бүлектәге** 3 бирем (1 – 3 нче биремнәр) укучыларның тыңлап аңлау күнекмәләрен тикшерүгә юнәлтелгән.

**2 нче бүлектәге** 2 бирем (4 – 5 нче биремнәр) укучыларның уку күнекмәләрен тикшерү максатыннан бирелә.

**3 нче бүлектәге** 3 бирем (6 – 8 нче биремнәр) укучыларның лексик-грамматик күнекмәләрен тикшерүгә кайтып кала.

**4 нче бүлектәге** 9 нчы бирем укучыларның язу күнекмәләрен тикшерү өчен бирелә.

**5 нче бүлек** биреме укучыларның телдән сөйләм күнекмәләрен тикшерүне күздә тота.

**Уңышлар телибез!**

**1 нче бүлек**

Текстны тыңлагыз һәм 1-3 нче биремнәрне эшләгез.

**1.** Кишер кайда үсә?

1) җир астында

2) яфрак астында

3) җир өстендә

**2.** Кишер нишли?

1) җир өстенә менә башлый

2) җир астына төшә башлый

3) җир астына төшә алмый

**3.** Бу – дөресме? *"Кәҗә кишерне ашарга тели" – дип әйтәләр.*

1) дөрес 2) дөрес түгел

**2 нче бүлек**

Җөмләләрне укыгыз. Дөрес сүзне сайлагыз. Астына сызыгыз.

**4.** Җәй көне (сез/без/алар) урманда ял итәбез.

**5.** (Кичен/иртән/төнлә) кояш чыккач та су коенырга чабабыз.

**3 нче бүлек**

Укыгыз һәм 6-8 нче биремнәрне эшләгез.

**6.** Басым беренче иҗеккә төшкән сүзне билгеләгез.

1) кайда
2) авыл
3) мәктәп

**7.**Аваз һәм аның билгеләмәсен тәңгәлләштерегез.

| | |
|---|---|
| А)[ә] | 1) сузык |
| Ә)[в] | 2) саңгырау тартык |
| Б) [к] | 3) яңгырау тартык |

Җавап

1)________ 2) ________ 3)____________

**8.** -*лар* кушымчасы ялгана торган сүзне күчереп языгыз.

*Гөл, елга, кеше.*

Җавап: _____________

**4 нче бүлек**

Укыгыз һәм җавапларны языгыз.

**9.** Сүзләрдән җөмлә төзеп языгыз. Беренче сүзне баш хәрефтән язып, җөмлә ахырында нокта куегыз.

коенам, җәй, мин, су, көне

**5 нче бүлек**

**10.** "Минем якын дустым" темасына бәйле 3 җөмлә уйлап әйтегез.

**Рус телендә белем бирү мәктәпләренең 1 нче сыйныф укучылары өчен
туган (татар) телдән
агымдагы аттестацияне уздыру
материалларының күрсәтмә варианты**

**Демонстрационный вариант
контрольных измерительных материалов для проведения
промежуточной аттестации
по родному (татарскому) языку для учащихся 1 классов
школ с русским языком обучения**

**Эшне башкару өчен күрсәтмә**

Биремнәрне башкару өчен, 25 минут вакыт бирелә. Тест 9 **биремне** үз эченә алган **5** бүлектән тора.

**1 нче бүлектәге** 3 бирем (1 – 3 нче биремнәр) укучыларның тыңлап аңлау күнекмәләрен тикшерүгә юнәлтелгән.

**2 нче бүлектәге** 2 бирем (4 – 5 нче биремнәр) укучыларның укукүнекмәләрен тикшерү максатыннан бирелә.

**3 нче бүлектәге** 3 бирем (6 – 7 нче биремнәр) укучыларның лексик-грамматик күнекмәләрен тикшерүгә кайтып кала.

**4 нче бүлектәге** 8 нче бирем укучыларның язу күнекмәләрен тикшерү өчен бирелә.

**5 нче бүлек** биреме укучыларның телдән сөйләм күнекмәләрен тикшерүне күздә тота.

**Уңышлар телибез!**

## 1 нче бүлек

Текстны тыңлагыз һәм 1-3 нче биремнәрне эшләгез.

1. Сания кая бара?

    1) кибеткә

    2) кунакка

    3) мәктәпкә

2. Сания кем белән бара?

    1) әнисе белән

    2) күрше белән

    3) дусты белән

**3.** Бу – дөресме?*Әнисенең сумкасында әйбер күп була*.

    1) дөрес                2) дөрес түгел

## 2 нче бүлек

Җөмләләрне укыгыз. Дөрес сүзне сайлагыз. Астына сызыгыз.

**4.** – Син (кичен/иртән төнлә) ниләр эшлисең?

**5.** – Мин йокыдан торам. Киенәм. Зарядка ясыйм. Аннан соң чәчемне (тарыйм/сөртәм/киптерәм).

## 3 нче бүлек

Укыгыз һәм 6-7 нче биремнәрне эшләгез.

**6.** Сузык авазны билгеләгез.

    1) [а]
    2) [л]
    3) [й]

**7.** Сүзләр һәм аның соравын тәңгәлләштерегез.

| | |
|---|---|
| А) төзүче | 1) нәрсә? |
| Ә) китап | 2) кем? |

Җавап:

1) ________2) ________

**4 нче бүлек**

Укыгыз һәм җавапларны языгыз.

**8.** Сүзләрдән җөмлә төзеп языгыз. Беренче сүзне баш хәрефтән язып, җөмлә ахырында нокта куегыз.

бабай, бирә, бүләкләр

**5 нче бүлек**

**9**. “Мин әниемә булышам” темасына бәйле 3 җөмлә уйлап әйтегез.

**Рус телендә белем бирү мәктәпләренең 3 нче сыйныф укучылары өчен туган (татар) телдән агымдагы аттестацияне уздыру материалларының күрсәтмә варианты**

**Демонстрационный вариант контрольных измерительных материалов для проведения промежуточной аттестации по родному (татарскому) языку для учащихся 3 классов школ с русским языком обучения**

**Эшне башкару өчен күрсәтмә**

Биремнәрне башкару өчен, 45 минут вакыт бирелә. Тест 11**биремне** үз эченә алган **5** бүлектән тора.

**1 нче бүлектәге** 3 бирем (1 – 3 нче биремнәр) укучыларның тыңлап аңлау күнекмәләрен тикшерүгә юнәлтелгән.

**2 нче бүлектәге** 2 бирем (4 – 5 нче биремнәр) укучыларның уку күнекмәләрен тикшерү максатыннан бирелә.

**3 нче бүлектәге** 3 бирем (6 – 9 нчы биремнәр) укучыларның лексик-грамматик күнекмәләрен тикшерүгә кайтып кала.

**4 нче бүлектәге**10 нчы бирем укучыларның язу күнекмәләрен тикшерү өчен бирелә.

**5 нче бүлек** биреме укучыларның телдән сөйләм күнекмәләрен тикшерүне күздә тота.

**Уңышлар телибез!**

**1 нче бүлек**

Текстны тыңлагыз һәм 1-3 нче биремнәрне эшләгез.

**1.** Шамил кая китәргә тиеш?
1) лагерьга
2) китапханәгә
3) кибеткә

**2.** Шамилнең әнисе нишли?
1) юа
2) укый
3) утыра

**3.** Бу – дөресме?*Камил ике-өч көннән лагерьга китәргә тиеш.*

1) дөрес 2) дөрес түгел

**2 нче бүлек**

Җөмләләрне укыгыз. Дөрес сүзне сайлагыз. Астына сызыгыз.

**4.** Без яз көне мәктәп (коридорына/бакчасына/ишегалдына) төрле яшелчәләр утырттык.

**5.** Җәй көне яшелчәләргә су (кердек/коендык/сиптек), чүп үләннәрен утадык.

**3 нче бүлек**

Укыгыз һәм 6-9 нчы биремнәрне эшләгез.

**6.** Исемне билгеләгез.

1) тәмле
2) пешерә
3) гөбәдия

**7.** ***Биек*** сүзенең антонимын билгеләгез.

1) зур
2) тәбәнәк
3) киң

**8.** Я хәрефе [йа] булып укыла торган сүзне күчереп языгыз.

*Яз, ярдәм, Сания.*

Җавап: _____________

**9.** Сүз һәм аның русчага тәрҗемәсен тәңгәлләштерегез.

| | |
|---|---|
| А) дус | 1) умный |
| Ә) акыллы | 2) друг |
| Б) күп | 3) много |

Җавап:

1)________ 2) ________ 3)____________

**4 нче бүлек**

Укыгыз һәм җавапларны языгыз.

**10.** Сүзләрдән җөмлә төзеп языгыз. Беренче сүзне баш хәрефтән язып, җөмлә ахырында нокта куегыз.

уеннар, уйныйлар, кешеләр, бәйрәмдә, күңелле

**5 нче бүлек**

**11**. “Минем бер көнем” темасына бәйле 3 җөмлә уйлап әйтегез.

**Рус телендә белем бирү мәктәпләренең 4 нче сыйныф укучылары өчен туган (татар) телдән агымдагы аттестацияне уздыру материалларының күрсәтмә варианты**

**Демонстрационный вариант контрольных измерительных материалов для проведения промежуточной аттестации по родному (татарскому) языку для учащихся 4 классов школ с русским языком обучения**

**Эшне башкару өчен күрсәтмә**

Биремнәрне башкару өчен, 45 минут вакыт бирелә. Тест 12 **биремне** үз эченә алган **5** бүлектән тора.

**1 нче бүлектәге** 3 бирем (1 – 3 нче биремнәр) укучыларның тыңлап аңлау күнекмәләрен тикшерүгә юнәлтелгән.

**2 нче бүлектәге** 2 бирем (4 – 5 нче биремнәр) укучыларның уку күнекмәләрен тикшерү максатыннан бирелә.

**3 нче бүлектәге** 3 бирем (6 – 10 нчы биремнәр) укучыларның лексик-грамматик күнекмәләрен тикшерүгә кайтып кала.

**4 нче бүлектәге** 11 нче бирем укучыларның язу күнекмәләрен тикшерү өчен бирелә.

**5 нче бүлек** биреме укучыларның телдән сөйләм күнекмәләрен тикшерүне күздә тота.

**Уңышлар телибез!**

**1 нче бүлек**

Текстны тыңлагыз һәм 1-3 нче биремнәрне эшләгез.

**1.** Бүген кемнең туган көне?
1) Фәридәнең
2) Фәридәнең әнисенең
3) Фәридәнең әбисенең

**2.** Әнисе нәрсә пешерде?
1) бәлеш
2) аш
3) торт

**3.** Бу – дөресме? *Дус кызлары иртәгә килер.*

1) дөрес 2) дөрес түгел

**2 нче бүлек**

Җөмләләрне укыгыз һәм 4-5 нче биремнәрне эшләгез.

**4.**Тышта ап-ак (яңгыр/боз/кар) ява.

**5.** (Агач/Чәчәк/Үлән) ботакларына мамыктай кар куна.

**3 нче бүлек**

Укыгыз һәм 6-10 нчы биремнәрне эшләгез.

**6.** Антонимнарны билгеләгез.
1) көзге, көзге
2) баллы, татлы
3) биек, тәбәнәк

**7.** I зат алмашлыгын билгеләгез.
1) ул
2) сез
3) без

**8.** Сүз һәм аның русчага тәрҗемәсен тәңгәлләштерегез.

| | |
|---|---|
| А) шәһәр | 1) земля |
| Ә) һәйкәл | 2) город |

Б) җир                                   3) памятник

Җавап:
1)________ 2) ________ 3)____________

**9.** Предмет һәм аның билгесен тәңгәлләштерегез.

А) үлән                                   1) эссе
Ә) шәһәр                                 2) зур
Б) көн                                    3) яшел

Җавап: 1) ________2) ________ 3)____________

**10.** Өч иҗекле сүзне күчереп языгыз.

*Ул ял көннәрендә көймәдә йөри.*

Җавап: _____________

**4 нче бүлек**

Укыгыз һәм җавапларны языгыз.

**11.** Сүзләрдән җөмлә төзеп языгыз. Беренче сүзне баш хәрефтән язып, җөмлә ахырында нокта куегыз.

уеннар, уйныйлар, кешеләр, бәйрәмдә, күңелле

**5 нче бүлек**

**12**. “Юл йөрү кагыйдәләре” темасына бәйле 3 җөмлә уйлап әйтегез.

**Рус телендә белем бирү мәктәпләренең 5 нче сыйныф укучылары өчен туган (татар) телдән агымдагы аттестацияне уздыру материалларының күрсәтмә варианты**

**Демонстрационный вариант контрольных измерительных материалов для проведения промежуточной аттестации по родному (татарскому) языку для учащихся 5 классов школ с русским языком обучения**

**Эшне башкару өчен күрсәтмә**

Биремнәрне башкару өчен, 45 минут вакыт бирелә. Тест 12 **биремне** үз эченә алган **5** бүлектән тора.

**1 нче бүлектәге** 3 бирем (1 – 3 нче биремнәр) укучыларның тыңлап аңлау күнекмәләрен тикшерүгә юнәлтелгән.

**2 нче бүлектәге** 2 бирем (4 – 5 нче биремнәр) укучыларның уку күнекмәләрен тикшерү максатыннан бирелә.

**3 нче бүлектәге** 3 бирем (6 – 10 нчы биремнәр) укучыларның лексик-грамматик күнекмәләрен тикшерүгә кайтып кала.

**4 нче бүлектәге** 11 нче бирем укучыларның язу күнекмәләрен тикшерү өчен бирелә.

**5 нче бүлек** биреме укучыларның телдән сөйләм күнекмәләрен тикшерүне күздә тота.

**Уңышлар телибез!**

**1 нче бүлек**

Текстны тыңлагыз һәм 1-3 нче биремнәрне эшләгез.

**1.** Бу кайсы вакыт?

1) көз

2) җәй

3) кыш

**2.** Урамда нәрсә ява?

1) кар

2) яңгыр

3) карлы яңгыр

**3.** Бу – дөресме? *Ишек төбендә бер мәче баласы уйный.*

1) дөрес 2) дөрес түгел

**2 нче бүлек**

Җөмләләрне укыгыз. Дөрес сүзне сайлагыз. Астына сызыгыз.

**4.** Кошларның күбесе, (җәйне/көзне/кышны) уздыру өчен, җылы якка очып китә.

**5**. Көзен җылы якка китә торган кошларны (ташлама/күчмә/канатлы) кошлар дип атыйлар.

**3 нче бүлек**

Укыгыз һәм 6-10нчы биремнәрне эшләгез.

**6.** Татар телендә генә булган авазны билгеләгез.

1) [в]
2) [й]
3) [ә]

**7.** Антонимнар кулланылган мәкальне билгеләгез.

1) Дус акчадан кыйммәт.
2) Аз сөйлә, күп эшлә.
3) Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз.

**8.** Ия һәм хәбәрне тәңгәлләштерегез.

А) җәй  1) каплады
Ә) үлән  2) уйныйлар
Б) балалар  3) җитте

Җавап:

1)________ 2) ________ 3)____________

**9.** Артыклык дәрәҗәсендәге сыйфатны күчереп языгыз.

*Куллар күшегүдән зәп-зәңгәр төскә кергән.*

Җавап: _____________________

**10.** Сүз ясагыч кушымча ялганган сүзне күчереп языгыз.

*Өйдә тәмле аш исе аңкый.*

Җавап: _____________

**4 нче бүлек**

Укыгыз һәм җавапларны языгыз.

**11.** 6 сүз өстәп, җөмләне тулыландырып языгыз.

Мин җәй көне ... .

**5 нче бүлек**

**12**. “Җәйге бер көнем” темасына бәйле 5 җөмлә уйлап әйтегез.

**Рус телендә белем бирү мәктәпләренең 6 нчы сыйныф укучылары өчен туган (татар) телдән агымдагы аттестацияне уздыру материалларының күрсәтмә варианты**

**Демонстрационный вариант контрольных измерительных материалов для проведения промежуточной аттестации по родному (татарскому) языку для учащихся 6 классов школ с русским языком обучения**

## Эшне башкару өчен күрсәтмә

Биремнәрне башкару өчен, 45 минут вакыт бирелә. Тест 13 **биремне** үз эченә алган **5** бүлектән тора.

**1 нче бүлектәге** 3 бирем (1 – 3 нче биремнәр) укучыларның тыңлап аңлау күнекмәләрен тикшерүгә юнәлтелгән.

**2 нче бүлектәге** 2 бирем (4 – 5 нче биремнәр) укучыларның уку күнекмәләрен тикшерү максатыннан бирелә.

**3 нче бүлектәге** 3 бирем (6 – 11 нче биремнәр) укучыларның лексик-грамматик күнекмәләрен тикшерүгә кайтып кала.

**4 нче бүлектәге** 12 нче бирем укучыларның язу күнекмәләрен тикшерү өчен бирелә.

**5 нче бүлек** биреме укучыларның телдән сөйләм күнекмәләрен тикшерүне күздә тота.

**Уңышлар телибез!**

## 1 нче бүлек

Текстны тыңлагыз һәм 1-3 нче биремнәрне эшләгез.

**1.** Гүзәл ничәнче сыйныфта укый?

1) дүртенче

2) бишенче

3) өченче

**2.** Илнур – кем ул?

1) Гүзәлнең әтисе

2) Гүзәлнең абыйсы

3) Гүзәлнең энесе

**3.** Бу – дөресме? *Илнур – түгәрәк йөзле малай.*

1) дөрес 2) дөрес түгел

## 2 нче бүлек

Җөмләләрне укыгыз. Дөрес сүзне сайлагыз. Астына сызыгыз.

**4.** Җәйнең күңелле көннәре үтеп (җитте/китте/бетте).

**5**. Табигатьтә көз билгеләре көннән-көн күзгә (азрак/күбрәк/сирәк) чалыналар.

## 3 нче бүлек

Укыгыз һәм 6-10нчы биремнәрне эшләгез.

**6.** Җөмләдәге сингармонизм законының рәт гармониясенә буйсынмаган сүзне билгеләгез.

*Илшат мәктәптә укый.*

1) Илшат

2) мәктәптә

3) укый

**7.** Парлы сүзне билгеләгез.

1) уен-көлке

2) гөлҗимеш

3) табышмак

**8.** Җәенке җөмләне билгеләгез.

1) Гүзәл укый, яза.
2) Яңгыр ява.
3) Зәңгәр чәчәкләр үсә.

9. Фигыль һәм аның заманын тәңгәлләштерегез.

| | |
|---|---|
| А) яна | 1) киләчәк заман хикәя фигыль |
| Ә) күренәчәк | 2) хәзерге заман хикәя фигыль |
| Б) киткәннәр | 3) үткән заман хикәя фигыль |

Җавап:

1)________ 2) ________ 3)____________

**10.** Француз теленнән кергән сүзне күчереп языгыз.

*Казан шәһәрендә метро ачылды.*

Җавап: ______________________

**11.** К е м? соравына җавап биргән сүзне күчереп языгыз.

*Абый урманга гөмбәгә бара.*

Җавап: ______________

**4 нче бүлек**

Укыгыз һәм җавапларны языгыз.

**12.** 6 сүз өстәп, җөмләне тулыландырып языгыз.
Яшел ... .

**5 нче бүлек**

**13**. “Минем апам (абыем)” темасына бәйле 5 җөмлә уйлап әйтегез.

**Рус телендә белем бирү мәктәпләренең 7 нче сыйныф укучылары өчен туган (татар) телдән агымдагы аттестацияне уздыру материалларының күрсәтмә варианты**

**Демонстрационный вариант контрольных измерительных материалов для проведения промежуточной аттестации по родному (татарскому) языку для учащихся 7 классов школ с русским языком обучения**

**Эшне башкару өчен күрсәтмә**

Биремнәрне башкару өчен, 45 минут вакыт бирелә. Тест 13 **биремне** үз эченә алган **5** бүлектән тора.

**1 нче бүлектәге** 3 бирем (1 – 3 нче биремнәр) укучыларның тыңлап аңлау күнекмәләрен тикшерүгә юнәлтелгән.

**2 нче бүлектәге** 2 бирем (4 – 5 нче биремнәр) укучыларның уку күнекмәләрен тикшерү максатыннан бирелә.

**3 нче бүлектәге** 3 бирем (6 – 11 нче биремнәр) укучыларның лексик-грамматик күнекмәләрен тикшерүгә кайтып кала.

**4 нче бүлектәге** 12 нче бирем укучыларның язу күнекмәләрен тикшерү өчен бирелә.

**5 нче бүлек** биреме укучыларның телдән сөйләм күнекмәләрен тикшерүне күздә тота.

**Уңышлар телибез!**

**1 нче бүлек**

Текстны тыңлагыз һәм 1-3 нче биремнәрне эшләгез.

**1.** Раушания кем ул?

1) сыйныфта иң матур кыз

2) Әхәтнең сеңлесе

3) Әхәтнең апасы

**2.** Әхәт кем ул?

1) Раушаниянең әтисе

2) Раушаниянең абыйсы

3) Раушаниянең сыйныфташы

**3.** Бу – дөресме? *Әхәтнең Раушания белән дуслашасы килә.*

1) дөрес 2) дөрес түгел

**2 нче бүлек**

Җөмләләрне укыгыз. Дөрес сүзне сайлагыз. Астына сызыгыз.

**4.** Физкультура мең төрле авыруга (каршы/дару/дәва), диләр.

**5**. Ни өчен физкультура шундый зур (көчне/көчкә/көчтән) ия соң?

**3 нче бүлек**

Укыгыз һәм 6-10нчы биремнәрне эшләгез.

**6.** Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзләрнең төрен билгеләгез.

***Алдыңа*** *бер карасаң,* ***артыңа*** *биш кара.* (Мәкаль)

1) синонимнар

2) антонимнар

3) омонимнар

**7.** Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең нинди җөмлә кисәге икәнлеген билгеләгез.

***Туры*** *сүз тимерне тишәр.* (Мәкаль)

1) аергыч
2) тәмамлык
3) хәл

**8.** Җыйнак җөмләне билгеләгез.
1) Бакчада алмалар өлгергән.
2) Бакчада кып-кызыл алмалар өлгергән.
3) Алмалар өлгергән.

9. Фигыль һәм аның төрен тәңгәлләштерегез.

| | |
|---|---|
| А) бүленегез | 1) шарт фигыль |
| Ә) бүленсә | 2) боерык фигыль |
| Б) бүленик | 3) теләк фигыль |

Җавап:

1)________ 2) ________ 3)____________

**10.** Сүзләрне укыгыз һәм [‘] (һәмзә) тартыгы кергән сүзне күчереп языгыз.

*Мәсьәлә, кәгазь, игътибар.*

Җавап: ______________________

**11.** Җөмләне укыгыз һәм сорау алмашлыгын күчереп языгыз.

*Их, нигә ял итәргә уйладым икән?*

Җавап: ______________

**4 нче бүлек**

Укыгыз һәм җавапларны языгыз.

**12.** 6 сүз өстәп, җөмләне тулыландырып языгыз.
Әнием, ... .

**5 нче бүлек**

**13**. “Тырыш укучы нинди була?” темасына бәйле 5 җөмлә уйлап әйтегез.

**Рус телендә белем бирү мәктәпләренең 8 нче сыйныф укучылары өчен туган (татар) телдән агымдагы аттестацияне уздыру материалларының күрсәтмә варианты**

**Демонстрационный вариант контрольных измерительных материалов для проведения промежуточной аттестации по родному (татарскому) языку для учащихся 8 классов школ с русским языком обучения**

**Эшне башкару өчен күрсәтмә**

Биремнәрне башкару өчен, 45 минут вакыт бирелә. Тест 13 **биремне** үз эченә алган **5** бүлектән тора.

**1 нче бүлектәге** 3 бирем (1 – 3 нче биремнәр) укучыларның тыңлап аңлау күнекмәләрен тикшерүгә юнәлтелгән.

**2 нче бүлектәге** 2 бирем (4 – 5 нче биремнәр) укучыларның уку күнекмәләрен тикшерү максатыннан бирелә.

**3 нче бүлектәге** 3 бирем (6 – 11 нче биремнәр) укучыларның лексик-грамматик күнекмәләрен тикшерүгә кайтып кала.

**4 нче бүлектәге** 12 нче бирем укучыларның язу күнекмәләрен тикшерү өчен бирелә.

**5 нче бүлек** биреме укучыларның телдән сөйләм күнекмәләрен тикшерүне күздә тота.

**Уңышлар телибез!**

**1 нче бүлек**

Текстны тыңлагыз һәм 1-3 нче биремнәрне эшләгез.

**1.** Кем тавышы ишетелә?

1) әнисенең

2) Сәмирәнең

3) Әмирнең

**2.** Әмир кая китә?

1) бакчага

2) мәктәпкә

3) киногa

**3.** Бу – дөресме? *Шатланып, юыну бүлмәсенә кереп китте.*

1) дөрес 2) дөрес түгел

**2 нче бүлек**

Җөмләләрне укыгыз. Дөрес сүзне сайлагыз. Астына сызыгыз.

**4.** Кеше табигать белән әүвәл заманнарда ук кызыксына (тотынган/җибәргән/башлаган).

**5**. Борынгы кешеләр үсемлекләр һәм хайваннар (өчен/шикелле/турында) мәгълүмат туплаганнар.

**3 нче бүлек**

Укыгыз һәм 6-10нчы биремнәрне эшләгез.

**6.** Шигырьдәге омонимнарның төрен билгеләгез.

*Чәчәкле җәй, чибәр җәй,*
*Юлыбызга чирәм җәй.* (Р.Миңнуллин)

1) саф
2) омоформалар
3) омофоннар

**7.** Җөмләдәге рәвешнең төркемчәсен билгеләгез.

*Имәндә чикләвек күп булса, кыш салкын килер.* (Сынамыш)
1) саф
2) урын
3) күләм-чама

**8.** Җөмләдәге хәл фигыльнең төрен билгеләгез.
Кеше кешене таныганчы, бер пот тоз ашый, ди. (Мәкаль)
1) II төр
2) III төр
3) IV төр

**9**. Теркәгечсез тезмә кушма җөмләнең хәбәрлекләрен үзара тәңгәлләштерегез.

| | |
|---|---|
| А) Яз хакимлек итә, | 1) яңгыр туктаган. |
| Ә) Таң беленә, | 2) агачлар яфрак ярган. |
| Б) Җил тына төшкән, | 3) офык алсуланган. |

Җавап:
1)________ 2) ________ 3)____________

**10.** Җөмләне укыгыз һәм юклык алмашлыгын күчереп языгыз.
*Җирдә тереклек үсеше берничә миллиард ел дәвам иткән.*
Җавап: ______________________

**11.** Кыек сөйләмле җөмләнең санын языгыз.
*1) Язгы җылы көннәрнең берсе иде. 2) Идрис бүлмәгә йөгереп кереп, сыерчыкларның килгән булуын әйтте. 3) Без икәүләп урамга чыктык.*
Җавап: ______________

## 4 нче бүлек
Укыгыз һәм җавапларны языгыз.

**12.** 7 сүз өстәп, җөмләне тулыландырып языгыз.
Тәрәзәгә каршы... .

## 5 нче бүлек
**13**. "Әти-әниемә минем ярдәмем" темасына бәйле 6 җөмлә уйлап әйтегез.

**Рус телендә белем бирү мәктәпләренең 9 нчы сыйныф укучылары өчен туган (татар) телдән агымдагы аттестацияне уздыру материалларының күрсәтмә варианты**

**Демонстрационный вариант контрольных измерительных материалов для проведения промежуточной аттестации по родному (татарскому) языку для учащихся 9 классов школ с русским языком обучения**

**Эшне башкару өчен күрсәтмә**

Биремнәрне башкару өчен, 45 минут вакыт бирелә. Тест 14 **биремне** үз эченә алган **5** бүлектән тора.

**1 нче бүлектәге** 3 бирем (1 – 3 нче биремнәр) укучыларның тыңлап аңлау күнекмәләрен тикшерүгә юнәлтелгән.

**2 нче бүлектәге** 2 бирем (4 – 5 нче биремнәр) укучыларның уку күнекмәләрен тикшерү максатыннан бирелә.

**3 нче бүлектәге** 3 бирем (6 – 12 нче биремнәр) укучыларның лексик-грамматик күнекмәләрен тикшерүгә кайтып кала.

**4 нче бүлектәге** 13 нче бирем укучыларның язу күнекмәләрен тикшерү өчен бирелә.

**5 нче бүлек** биреме укучыларның телдән сөйләм күнекмәләрен тикшерүне күздә тота.

**Уңышлар телибез!**

**1 нче бүлек**

Текстны тыңлагыз һәм 1-3 нче биремнәрне эшләгез.

**1.** Кыңгырау чыңлаганда, кызлар кайда иде?

1) китапханәдә

2) ашханәдә

3) сыйныф бүлмәсендә

**2.** Кызлар мәктәп ашханәсендә нишлиләр иде?

1) чәй эчәләр иде

2) ботка ашыйлар иде

3) телефонда уйныйлар иде.

**3.** Бу – дөресме? *Укытучыдан курыкканга, география дәресенә йөгерәләр.*

1) дөрес 2) дөрес түгел

**2 нче бүлек**

Җөмләләрне укыгыз. Дөрес сүзне сайлагыз. Астына сызыгыз.

**4.** "Якты күл" (иске, борынгы, күптәнге) күл инде ул. (Ф.Сафиннан)

**5**. Күл яр читендә балык (тотып, чүпләп, сөзеп) утырган малайларны бигрәк якын итте. (Ф.Сафиннан)

**3 нче бүлек**

Укыгыз һәм 6-10 нчы биремнәрне эшләгез.

**6.** Җөмләдәге басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзне билгеләгез.

*Дөрес сөйләгән ялгышмый.* (Мәкаль)

1) дөрес

2) сөйләгән

3) ялгышмый

**7.** Фразеологизмның татарча тәрҗемәсен билгеләгез.

*Найти общий язык*

1) уртак тел табу
2) башы күккә тию
3) авызга су кабу

**8.** Сыйфат фигыль кулланылган мәкальне билгеләгез.
1) Укыган кеше хур булмас.
2) Надан белмәсә дә кычкыра.
3) Надан кеше – сукыр тавык.

**9**. Теркәгечне һәм аның төрен тәңгәлләштерегез.

| | |
|---|---|
| А) һәм | 1) каршы куючы |
| Ә) ләкин | 2) җыючы |
| Б) яки | 3) бүлүче |

Җавап:

1)________ 2) ________ 3)____________

**10.** Сүз һәм аның кушымча төрен тәңгәлләштерегез.

| | |
|---|---|
| А) урталай | 1) сүз ясагыч |
| Ә) кызгылт | 2) бәйләгеч |
| Б) ипине | 3) модальлек |

Җавап:

1)________ 2) ________ 3)____________

**11.** Җөмләдәге хәбәрне күчереп языгыз.

*Малайлар, кәшәкә сыман таякларын алып, күлгә таба йөгерделәр.* (Й.Шәрәпова)

Җавап: _____________________

**12.** Җөмләдәге зат алмашлыгын күчереп языгыз.

*Шуңа күрә дә без Китапка чиксез рәхмәтле.* (Р.Миңнуллин)

Җавап: _____________

**4 нче бүлек**

Укыгыз һәм җавапларны языгыз.

**13.** 8 сүз өстәп, җөмләне тулыландырып языгыз.

Спортзалда ... .

**5 нче бүлек**

**14**. “Безнең мәктәп” темасына бәйле 6 җөмлә уйлап әйтегез.

**10-11 нче сыйныф укучылары өчен туган (татар) телдән**
**агымдагы аттестацияне уздыру материалларының күрсәтмә варианты**

**Демонстрационный вариант**
**контрольных измерительных материалов для проведения**
**промежуточной аттестации**
**по родному (татарскому) языку для учащихся 10-11 классов**

**Эшне башкару өчен күрсәтмә**

Биремнәрне башкару өчен, 45 минут вакыт бирелә. Тест 15 **биремне** үз эченә алган **5** бүлектән тора.

**1 нче бүлектәге** 3 бирем (1 – 3 нче биремнәр) укучыларның тыңлап аңлау күнекмәләрен тикшерүгә юнәлтелгән.

**2 нче бүлектәге** 2 бирем (4 – 5 нче биремнәр) укучыларның уку күнекмәләрен тикшерү максатыннан бирелә.

**3 нче бүлектәге** 3 бирем (6 – 13 нче биремнәр) укучыларның лексик-грамматик күнекмәләрен тикшерүгә кайтып кала.

**4 нче бүлектәге** 14 нче бирем укучыларның язу күнекмәләрен тикшерү өчен бирелә.

**5 нче бүлек** биреме укучыларның телдән сөйләм күнекмәләрен тикшерүне күздә тота.

**Уңышлар телибез!**

**1 нче бүлек**

Текстны тыңлагыз һәм 1-3 нче биремнәрне эшләгез.

**1.** Рәсим кемнең ручкасына кызыкты?

1) Илһамның

2) Илгизәнең

3) укытучының

**2.** Рәсим ручканы кайчан ала?

1) дәрес беткәч

2) дәрес вакытында

3) укырга килгәч

**3.** Бу – дөресме? *Илһамның ручкасы бизәкләп, сырлап эшләнгән.*

1) дөрес 2) дөрес түгел

**2 нче бүлек**

Җәя эчендәге сүзләрнең дөресен сайлап укыгыз. Дөрес сүзнең астына сызыгыз.

**4.** Урмандагы алан (кебек, буйлап, дип) Керпе бара. (Ф.Сафиннан)

**5.** Кая (карама, күрмә, тыңлама), кыштырдавык яфраклар. (Ф.Сафиннан)

**3 нче бүлек**

Укыгыз һәм 6-13 нче биремнәрне эшләгез.

**6.** Калын сузык авазлардан гына торган мәкальне билгеләгез.

1) Курыккан эт койрыгын кысар.
2) Батыр үз халкын яклый.
3) Батырларга юл туры.

**7.** ***Тәнкыйть*** сүзендә нечкәлек билгесенең язылышын билгеләгез.

1) соңгы тартыкны нечкә итеп әйтү өчен
2) сүзне нечкә итеп әйтү өчен

3) иҗекне нечкә итеп әйтү өчен

**8.** Кушма җөмләдәге компонентлар арасындагы бәйләүче чараны билгеләгез.

*Күз ясармын, зәңгәр буяу*
*Табалсам әгәр,*
*Чөнки синең күзләрең бит*
*Сагыштай зәңгәр.* (Р.Вәлиев)

1) чөнки
2) -са
3) әгәр

**9.** Җөмләдәге ияне күчереп языгыз.

*Икенчедән, компьютерның милләте юк.* (Р.Миңнуллин)

Җавап: ______________________

**10.** Җөмләдәге хикәя фигыльне күчереп языгыз.

*Бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән кулъязма китаплар шул хакта сөйли.* (Р.Миңнуллин)

Җавап: ______________

**11.** Җөмләдәге кушма сүзне күчереп языгыз.

*Кулъязмаларны күчереп язучы осталар барлыкка килгән.* (Р.Миңнуллин)

Җавап: _____________

**12**.Мәкальнең беренче һәм икенче өлешен тәңгәлләштерегез.

| | |
|---|---|
| А) Кеше акылын ишет, | 1) кешене тыңла. |
| Ә) Үз акылың җитмәсә, | 2) бәхетең киң булыр. |
| Б) Күңелең иркен булса, | 3) үзеңнеке белән эш ит. |

Җавап:

1)________ 2) ________ 3)_____________

**13.** Фразеологизм һәм аның русчага тәрҗемәсен тәңгәлләштерегез.

А) һавадан алып сөйләү 1) задать стрекоча

Ә) табан ялтырату
Б) колакка киртеп кую

2) зарубить себе на носу
3) высосать из пальца

Җавап:

1)________ 2) ________ 3)____________

## 4 нче бүлек

**14. «Иң батыр кеше – үз нәфесен җиңүче»** мәкалендә әйтелгән фикерне сез ничек аңлыйсыз? Шулар турында 30 сүздән дә ким булмаган инша языгыз.

Язма эшегез чиста һәм танырлык булсын.

## 5 нче бүлек

**15**. **«Кыңгыраулы мәктәп еллары»** темасына бәйләнешле 8 җөмлә уйлап әйтегез.

**ҖАВАПЛАР**

**1 СЫЙНЫФ**

| **1 вариант** | |
|---|---|
| Сорау номеры | җаваплар |
| 1 | 1 |
| 2 | 1 |
| 3 | 1 |
| 4 | иртән |
| 5 | тарыйм |
| 6 | 1 |
| 7 | 21 |
| 8 | Бабай бүләкләр бирә |

**Аудиотекстлар**

**1 вариант**

Кайчакта Сания әнисе белән күрше кибеткә керә. Кибеттән чыкканда, әнисенең сумкасы әйбер белән тулы була.

– Әни, мин дәү үстем инде, сумканы мин күтәрим, миңа бир, – ди ул.

Әнисе:

– Әйдә, икәү күтәрик, – ди.

Урамдагы кешеләр, моны күреп: «Ай-яй, нинди зур үскән бу кыз! Әнисенә ничек булыша!» – дигән кебек елмаеп калалар. (Г.Бакирдан)

**ҖАВАПЛАР**

**2 СЫЙНЫФ**

| **1 вариант** | |
|---|---|
| Сорау номеры | җаваплар |
| 1 | 1 |
| 2 | 2 |
| 3 | 2 |
| 4 | без |
| 5 | иртән |
| 6 | 1 |
| 7 | 132 |
| 8 | ЕЛГА |
| 9 | Җәй көне мин су коенам |

**Аудиотекстлар**

**1 вариант**

Беләсезме, кишер ни өчен җир астында үсә? Тыңлагыз, сөйлим.

Бервакыт кишергә: “Куян сине ашарга тели”, – дип әйтәләр.

Нишләргә? Кайда яшеренергә?

Озак уйлап тормый кишер, ашыга-ашыга, җир астына төшә башлый. Бөтенләй җир астына төшеп булмый бит. Ничек суларсың анда? Кишер башын гына калдыра, аны үзенең яфраклары белән каплап куя. Шуннан бирле кишер җир астында гына үсә икән, ди. (З.Әхмәровтан)

**ҖАВАПЛАР**

**3 СЫЙНЫФ**

| **1 вариант** | |
|---|---|
| Сорау номеры | җаваплар |
| 1 | 1 |
| 2 | 1 |
| 3 | 2 |
| 4 | бакчасында |
| 5 | сиптек |
| 6 | 3 |
| 7 | 2 |
| 8 | ЯЗ |
| 9 | 213 |
| 10 | Бәйрәмдә кешеләр күңелле уеннар уйныйлар |

**Аудиотекстлар**

**1 вариант**

Шамил ике-өч көннән лагерьга китәргә тиеш иде. Юл хәзерлекләре башланды. Әнисе аның кием-салымнарын юарга тотынды. Шамил әнисенә булышты. Шуннан соң гына агач төбендәге эскәмиягә утырды да китапханәдән алып кайткан китабын укый башлады.

Көн матур, кояшлы иде. Яшел яфраклы тирәк агачларыннан тәмле ис аңкып тора. Бал кортлары сирень чәчәкләреннән, тырышып-тырышып, бал эзлиләр. Шамил укый башлаган китабын куйды да шул гаҗәп тырыш бөҗәкләргә бик озак карап торды. (Г.Бакировтан)

**ҖАВАПЛАР**

**4 СЫЙНЫФ**

| **1 вариант** | |
|---|---|
| Сорау номеры | җаваплар |
| 1 | 1 |
| 2 | 3 |
| 3 | 2 |
| 4 | кар |
| 5 | агач |
| 6 | 3 |
| 7 | 3 |
| 8 | 231 |
| 9 | 321 |
| 10 | КӨЙМӘДӘ |
| 11 | Мин көзге каникулда сәяхәт итәм |

**Аудиотекстлар**

**1 вариант**

Бүген Фәридәнең туган көне. Әнисе торт пешерде.

Өстендәге күлмәге бик матур бүген Фәридәнең. Ап-ак ефәккә зәңгәр борчаклар төшкән.Анысын да әнисе текте аңа. Ул Фәридәнең чәчләренә зәп-зәңгәр тасма такты.

Өйләре дә искиткеч матур. Фәридә тирә-якка күз йөртеп чыкты. Бар да шундый матур, шундый күңелле! Тиздән аның дус кызлары килеп җитәр...

Фәридә әнисе янына аш бүлмәсенә керде.

— Әни, әни, әйдә, әби бүгенгә генә залга, минем кунакларым янына чыкмасын, ә? Югыйсә, бүген анда бөтен нәрсә шундый матур, шундый яңа, ә әби шундый иске, шундый карт... бер дә килешми.

Әнисе башта аңламыйча торды. Аның йөзе бөтенләй үзгәргән, зур күзләре тирәнәеп, каралып киткәндәй булган иде.

— Менә нәрсә, Фәридә, дусларыңа шалтыратып әйт: бүген туган көнеңне уздырмыйбыз. Менә шулай, уздырмыйбыз... – диде ул.

Фәридә сүзсез калып торды. Йөзе кызарды, керфекләре дерелдәп-дерелдәп куйдылар.Кинәт аңа әнисе алдында бик тә оят булып китте

(Р.Вәлиевадан)

**ҖАВАПЛАР**

**5 СЫЙНЫФ**

| **1 вариант** | |
|---|---|
| Сорау номеры | җаваплар |
| 1 | 1 |
| 2 | 3 |
| 3 | 2 |
| 4 | кышны |
| 5 | күчмә |
| 6 | 3 |
| 7 | 2 |
| 8 | 312 |
| 9 | ЗӘП-ЗӘҢГӘР |
| 10 | ТӘМЛЕ |

**Аудиотекстлар**

**1 вариант**

Урамда көз. Карлы яңгыр ява. Биек йортның ишек төбендә бер мәче баласы калтыранып утыра. Ул нык өшегән, тизрәк җылыга керәсе килә. “Мияу, мияу, зинһар, ишекне ачыгыз!” – дип ялвара. Тик ишек ачылмый.

Әнисе белән үтеп баручы бер нәни кыз песине кулына алды.

— Куй! Курткаңны пычратасың, - дип ачуланды әнисе.

— Куртканы юып була, ә песи өшеп үлсә, аны терелтеп булмый, - диде кыз.

Әнисе елмайды:

— Алайса курткаңны үзең юарсың.

Кыз мәче баласын күкрәгенә кысты:

— Ярар, әнием, юармын. Песине дә үзем карармын.

Өчесе дә шат, бәхетле иде. (Р.Габделхакова)

**ҖАВАПЛАР**

**6 СЫЙНЫФ**

| **1 вариант** | |
|---|---|
| Сорау номеры | җаваплар |
| 1 | 1 |
| 2 | 3 |
| 3 | 1 |
| 4 | китте |
| 5 | күбрәк |
| 6 | 1 |
| 7 | 1 |
| 8 | 3 |
| 9 | 213 |
| 10 | МЕТРО |
| 11 | АБЫЙ |

**Аудиотекстлар**

**1 вариант**

Дүртенче сыйныфта гына укыса да, Гүзәл инде апа кеше. Аның үзе шаян, үзе шук Илнур исемле энесе бар. Түгәрәк йөзле, тып-тып басып йөрүче шул малай яратып, якын итеп “Гүзәл апа” дип дәшә аңа.

Апалы-энеле ике туган бик тату, бик дус яшиләр. Һәркөн иртән әниләре белән берсе – мәктәпкә, икенчесе бакчага бара. Күп тә түгел, аз да түгел – көн буена гына аерылышып торалар, югыйсә. Әмма сагынышырга өлгерәләр. Өйгә кайткач, Гүзәл Илнурга мәктәптә күргәннәрен, нинди дәресләр булганын, нинди билгеләр алганын сөйли. Энесе апасына бакчада үзе уйнаган аю малайлары, төлке кызлары турында тәтелди. Аларның әллә нинди кызык хәлләр хакында сөйләшүләрен әйтеп кенә бетерерлекмени соң?! Еш кына энесен бакчадан Гүзәл кереп ала. Кайчак әнисе белән әтисе я эштә тоткарлана, я кибеткә керәселәре була.

Бүген дә Илнурны бакчадан апасы алып кайтырга булды. Үзе кебек кечкенә малайлар, кызлар белән уйнап утырган малай апасын күргәч йөгереп, аның янына килде.

Ниһаять, апасы ярдәм иткәч, Илнур киенеп тә өлгерде. Әйтерсең, катлы-катлы кәбестә булды. Тик сез көләргә ашыкмагыз! Урамда кыш бит, салкын. Кечкенәләргә тунарга ярамый. Туңсаң авырыйсың. Авырсаң, бакчага бара алмыйсың. Бакчага бармыйсың икән, әниең өйдә утырырга тиеш. Ә әниләргә эштән калырга ярамый. (Р.Гыйззәтуллин)

**ҖАВАПЛАР**

**7 СЫЙНЫФ**

| **1 вариант** | |
|---|---|
| Сорау номеры | җаваплар |
| 1 | 1 |
| 2 | 3 |
| 3 | 1 |
| 4 | дәва |
| 5 | көчкә |
| 6 | 2 |
| 7 | 1 |
| 8 | 3 |
| 9 | 213 |
| 10 | МӘСЬӘЛӘ |
| 11 | НИГӘ |

**Аудиотекстлар**

**1 вариант**

Раушания – сыйныфта иң матур кыз. Моның шулай икәнлеген бөтенебез белә. Әхәт тә белә, ләкин белеп кенә ни файда? Менә Раушания Әхәтне матур итеп күрсен иде ул. Юк шул! Әз генә дә игътибар итми. Бәлки, игътибар да иткән булыр иде – Әхәтнең колаклары зур, көзге әче җилләрдә тирбәлгән әрекмән яфраклары шикелле селкенеп торалар. Буе да бик кечкенә. Әнисенең кер юу машинасыннан әз генә биегрәк. Ләкин бик дуслашасы килә шул Раушания белән.

Их, берәр батырлык эшләсәң иде ул! Әйтик, Раушания суга бата башлый... Әхәт аны коткара... Яисә кызны зур овчарка таларга җыена. Шунда Әхәт йөгереп килә дә, “рраз!”, “рраз!”... Хыялларның чиге-чамасы юк иде.

Беркөнне Әхәтне, Раушанияне һәм сыйныфтагы тагын өч укучыны район үзәгенә математика буенча уздырылган олимпиадага җибәрделәр. Олимпиада яхшы узды. Соңыннан, барысы бергә кереп, ашханәдә тамак

ялгадылар. Ашаганнан соң, укытучы апалары берәр сәгать ял итәргә рөхсәт бирде. Шунда Әхәт:

- Раушания, әйдә, әнә теге супермаркетка барып киләбез, - диде, бераз дулкынланып. Кыз риза булды.

Теләгән әйберләрен алып, кибеттән чыгып барганда, көтмәгәндә, алар каршына Әхәттән дә бәләкәйрәк буйлы бер малай килеп басты.

- Сәлам, чибәркәй, телефоның бармы? Бир аны миңа! Тизрәк! – диде ул.

Әхәт катты да калды. Нәрсәдер әйтергә теләп авызын ачты... әмма дерелдәгән иреннәре арасыннан сүз чыкмады.

Шунда Раушания кулындагы сумкасы белән хулиган малайга китереп сукты. Ялгыш кына Әхәткә дә эләкте. Бу тавышка кибет эченнән кешеләр йөгереп чыкканда, бәләкәй буйлы башкисәр табан ялтыраткан иде инде. Раушания асфальтта башын тотып утырган Әхәт янына чүгәләде дә:

- Авыртамы? Гафу ит, ялгыш эләкте, - диде. (А.Гыймадиев)

**ҖАВАПЛАР**

**8 СЫЙНЫФ**

| **1 вариант** | |
|---|---|
| Сорау номеры | җаваплар |
| 1 | 1 |
| 2 | 2 |
| 3 | 2 |
| 4 | башлаган |
| 5 | турында |
| 6 | 2 |
| 7 | 3 |
| 8 | 3 |
| 9 | 231 |
| 10 | БЕРНИЧӘ |
| 11 | 2 |

**Аудиотекстлар**

**1 вариант**

— Улым, биш минуттан киенеп беткән бул!

— Әмир, сумкаң һаман тулмаганмени әле?!

Бусы – әни тавышы. Ачулы. Торырга кирәк.

Малай күзен смартфон экраныннан аерырга мәҗбүр булды. Үпкәле кыяфәт белән әкрен генә юыну бүлмәсенә кереп китте. Ишекне каты итеп ябарга да онытмады. Кранны борды. Аннан саргылт төстәге су ага башлады. Тагын җылы суны туктаталар, димәк. Юынырга өлгерми калды.

Әнисе ишекне ябып чыгып китте. Әтисе, алданрак чыгып, машинаны җылыта тора. Сеңлесе Сәмирә дә аларга иярә. Аны бакчага кертәсе бар.

Малай сәгатькә карады – 7:30 икән инде. Киенергә кирәк.

Галиевләр гаиләсендә чираттагы гадәти көн башланды.

Мәктәп — мәктәп инде. Укысаң да барасы, укымасаң да. Иң начары – өй эшләре бирәләр. Әмирнең өйдә ни эшләвендә кемнең ни эше бар?! Дәрес укып кайттыңмы – бетте! Калганы кешенең шәхси вакыты ич. Нишләп әле малай үзенең буш вакытын мәсьәлә чишеп үткәрергә тиеш?! Һич дөрес түгел бу! Әмирнең чәче җитеп килгән башында менә шундый уйлар бунт күтәрә. Еш кына өй эшләрен эшләми дә бара ул мәктәпкә. (Л.Гыйбадуллина)

**ҖАВАПЛАР**

**9 СЫЙНЫФ**

| **1 вариант** | |
|---|---|
| Сорау номеры | җаваплар |
| 1 | 2 |
| 2 | 1 |
| 3 | 2 |
| 4 | борынгы |
| 5 | тотып |
| 6 | 3 |
| 7 | 1 |
| 8 | 1 |
| 9 | 213 |
| 10 | 132 |
| 11 | ЙӨГЕРДЕЛӘР |
| 12 | БЕЗ |

**Аудиотекстлар**

**1 вариант**

— Аңларбыз микән без, юкмы бу математиканы, тәмам туйдырып бетерде бит. Сынауларга әзерли, имеш.

— Алай димә инде. Ул безгә бары тик яхшылык тели. Башкача укымыйбыз ич без.

Гүзәл белән мәктәп ашханәсендә чәй эчеп, сөйләшеп утыра идек, дәрескә кыңгырау чыңлады. Дәррәү сыйныфка йөгердек. Юк, укытучының шелтәләвеннән куркып түгел, бары тик яраткан дәресебез булганга. Географиядән безне Галия апа укыта. Галия Миркасыймовнаны һәркем белә, ул дәресләрне төрле кызык хәлләр белән үреп алып бара.

Авыл мәктәбе — авыл мәктәбе инде. Сталин заманыннан калган иске карталар таушалып беткән. Читләренә кәгазь кисәкләре ябыштырылган. Урта бер тирәдә шулай ук “ямау” күренә. Берәү, бик тырышып, Таллин шәһәрен күрсәткән бугай, тишелеп үк чыккан. Анда да шакмаклы дәфтәр бите ябыштырып куйганнар.

Галия апа бүген тактага һәрнәрсәдән кызык табарга яратучы Илһамны чыгарды.

— Җәйге каникулдагы шат хисләрдән бераз арынып, картаны кабатлап алыйк әле. Мин дәүләтне әйтәм, син башкаласын тап һәм күрсәт.

Илһам тактага чыккач, иркенләп утырсаң да була. Чөнки ул аннан тиз генә кермәячәк, хәтта дәреснең бетү ихтималы да бар.

Бик озак азапланды ул карта янында. Бары тик Мәскәүне һәм Пекинны күрсәтә алды. Ә Австралиянең башкаласы Австрия икәнен белеп, көлә-көлә, дәрестән чыгып киттек. Дәрес ахырында апа:

— Сынаулар дип артык борчылмагыз. Тугызның сынаулары авыр түгел ул. Болай да бөтен яшьлегеңне укуга бирәсең. Нәтиҗәсе булса ярый да бит... Күпме кеше кызыл дипломын кочаклап өйдә утыра, кайберләре ике югары белем белән чәй әзерләп йөри. Бу сынаулар чүп кенә ул. Ә менә тормыш сынауларында сыгылмый калу – чын батырлык! – диде.

— Тагын җиде ай бар бит, барысы да алда әле, - диештек.

Галия апаның бу сүзләрен аңламаган идем. Мәгънәсен тора-бара язмыш үзе төшендерде... (А.Нургатина)

## ҖАВАПЛАР

## 10-11 СЫЙНЫФ

| **1 вариант** | |
|---|---|
| Сорау номеры | җаваплар |
| 1 | 1 |
| 2 | 1 |
| 3 | 1 |
| 4 | буйлап |
| 5 | карама |
| 6 | 3 |
| 7 | 3 |
| 8 | 1 |
| 9 | МИЛЛӘТЕ |
| 10 | СӨЙЛИ |
| 11 | КУЛЪЯЗМАЛАРНЫ |
| 12 | 312 |
| 13 | 312 |

## Аудиотекстлар

### 1 вариант

Рәсим күтәрелеп караган иде, алгы партада утырган Илһамның ручкасына күзе төште. Гади генә түгел, бизәкләп, сырлап ясалган иде ул. Тәрәзәдән сузылган кояш нурларында алтындай елык-елык килә. Әлеге нурлар Рәсимне: “Синең андый ручкаң юк”, - дип үчеклиләр сыман иде.

Дәресләр тәмамлануын белдереп, кыңгырау шалтырады. Рәсим ашыкмый-кабаланмый урыныннан торда. Сумкаларына дәфтәр, китапларын тутыру белән мәшгуль булган Илһам ручкасының юкка чыкканын сизми дә калды. Рәт арасыннан узганда, Рәсим ручканы эләктергән иде инде. Ничек шулай оста, тиз эләктергәндер, соңыннан үзе дә гаҗәпләнде ул моңа. Илһам, берни сизмичә, сумкасын күтәреп, сыйныф бүлмәсеннән чыгып китте.

Рәсимнән дә бәхетле малай юк иде бу минутларда. Бизәкле ручка аның кесәсендә иде.

Өйләренә дә алтын кош тоткандай очынып кайтып керде. Кесәсеннән ручканы алып карый башлады. Бик матур, язарга да уңайлы. Тик куанычы озакка бармады. Янәшәсенә сеңелесе Илгизә килеп басты да кычкырып:

- Нинди матур ручка! Кайдан алдың, абый? – дип кычкырды.

Бу көтелмәгән сорауга җавап бирә алмады Рәсим. Алгы бүлмәдән әнисе чыкты. Ул да, улы кулындагы ручканы күреп, шул ук сорауны кабатлады. Рәсим тәмам коелып төште. Җавап бирә алмый, башын аска иеп басып тора. Йөзе кып-кызыл.

- Кеше әйберенә тигәнсең, улым! Кара аны, хуҗасына илтеп бир, - диде әнисе һәм, кисәк кенә борылып, бүлмәдән чыгып китте.

Рәсим ручкага карады, ул элеккечә балкып күренми иде инде.

Икенче көнне Рәсим класска иң беренче булып килеп керде. Керүгә ручканы Илһамның партасына куйды. Озакламый бер-бер артлы сыйныфташлары да килә башлады. Ниһаять, ишектә Илһам да күренде. Ул ручкасын күргәч, балкып, елмаеп җибәрде.

- Онытып калдырганмын икән ич. Югалттым дип уйладым, - дип әйтте ул. – Абыем бүләге.

Рәсим, хуҗасы кулына күчкәннән соң яңадан элеккечә балкып торган ручкага карап, җиңел сулап куйды. (Р.Гыйззәтуллин)

Өйгә кайтып, букчаны бушатканда, Алия төреп салган икмәк кисәкләре арасыннан шапылдап авыр саплы пәке килеп төште.

Өс-башымны да алыштырмадым, пәкене эләктереп, Диләрәләргә чаптым. Элек Рүзәлләргә кердем, сөенчене башта аңа әйтергә булдым.

Әмма Рүзәл мине хупламады.

- Син, Сәет, Диләрәгә күрсәтмә инде аны хәзер, - диде. – Букчаңа ялгыш кергәнлеккә ничек ышандырырсың аны...

Мин икеләнеп калдым. Рүзәл – иң якын дустым, миңа зыянга сөйләмәс. Дөрес, кызларда миңа карата шик туса, гаебең юклыгын ничек аңлатырсың? Алия аңлар, кечкенәдән бергә уйнап үскән кыз. Минем букчага үз куллары белән салды бит ризык төргәген. Анысын үзе дә әйтер. Менә Диләрәсе... Бик

үткен кыз ул, кимчелегеңне йөзеңә бәреп әйтә. Шамилләр, Әнвәрләр, кешенең тырнак очы кадәр гаебен күрсәләр дә, бөтен дөньяга кычкыралар.

Шулай да пәкене үземдә калдыра алмыйм бит инде.

- Әйдә минем белән, - дидем Рүзәлгә. – Син бит минем кеше әйберенә тимәгәнлегемне беләсең, шикләнсәләр, алатырсың.

Дустым авырсынып кына риза булды.

- Син бара тор, куып җитәрмен, - диде.

Барганда, Алиягә дә кереп әйттем.

Шамил белән Әнвәр кайтканда, Диләрәләр капка төбендә туктаганнар икән.

- Менә, минем әйберләр арасыннан килеп чыкты, - дип, пәкене Диләрәгә суздым. Үзем артымнан килүче Алиягә карадым. Тик ул дәшмәде. Киресенчә, күзләрен миннән яшергән сыман тоелды. Диләрә куанычыннан кычкырып җибәрде. Егетләр дә шатланды, өстәвенә, мине мактый башладылар:

- Рәхмәт, Сәет, әле дә күреп алгансың, югыйсә, абыйсы ачуланыр иде.

Кечкенәдән бергә уйнап үскән Алия генә дәшмәде. Иң якын дустым Рүзәл дә никтер һаман күренмәде. (Л.Гыймадиева)